**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** с. Тюлячи **БОЕРЫК**

«12» апрель 2018 № 143

Муниципаль мәдәният учрежденияләре территорияләрен төзекләндерү һәм тәртипкә салу буенча ел саен район күләмендә уздырыла торган конкурс нигезләмәсен раслау турында

2018 елның 4 апреленнән 21 нче номер астында чыккан район Башкарма комитеты мәдәният бүлеге җитәкчесе хатын карап, “Россия Федерациясендә җирлек үзидарәсеннән оештыруның булган гомуми принциплары турында” 2003 елның 5 октябереннән 131 нче номерлы Федераль закон нигезендә,

1. Муниципаль мәдәният учрежденияләре территорияләрен төзекләндерү һәм тәртипкә салу буенча ел саен район күләмендә уздырыла торган конкурс нигезләмәсен расларга, кушымта нигезендә.

2. «Татмедиа» ААҖ «Теләчеинформ» мәгълүмат үзәгенә (Хуҗин Л.Й.) конкурс чараларын үткәрү турында җирле массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәкъдим итәргә.

3. Күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенен социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Галеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хамидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
“12” 04 2018 елның № 143
боерыгына кушымта

Мәдәният учреждениеләре арасында территорияне төзекләндерү буенча ел саен үткәрелүче район конкурсына Нигезлэмэ

1. Гомуми нигезләмәләр

Мәдәният учреждениеләре арасында территорияне төзекләндерү буенча ел саен үткәрелүче район бәйгесе Теләче муниципаль район башкарма комитетының мәдәният бүлеге тарафыннан уздырыла. Нигезләмә конкурсны үткәрү тәртибен билгели.

Теләче муниципаль район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге конкурска бирелгән материалларны учреждение җитәкчесенең язма ризалыгы белән «Теләче» район газетасында һәм Интернетта урнаштыру максатыннан файдаланырга хокуклы.

Территорияне төзекләндерү буенча районда үзучы конкурста урыннар түбәндәге төркемнәр буенча чыгарыла:

- авыл мәдәният йортлары һәм авыл клублары;
- китапханәләр.

2. Конкурсның максаты һәм бурычлары

Конкурсның максатлары һәм бурычлары:

- мәдәният учреждениеләре һәм халык күпләп ял итә торган территорияләрне санитар чистарту буенча чаралар уздыру;
- район мәдәният учреждениеләрендә халыкның ялын оештыру;
- җитештерү һәм куллану калдыклар белән эш итү кагыйдәләрен һәм таләпләрен үтәү;
- бина фасадларын, тирә-як территорияләрне тәртипкә китерү, төзекләндерү;
- китапханә һәм клуб учреждениеләре хезмәткәрләренең эстетик зәвыгын формалаштыру.

3. Конкурсның шартлары һәм үткәрү вакыты

Конкурсны әзерләү һәм уздыру өчен конкурс комиссиясе составын мәдәният бүлеге булдыра һәм аны боерык нигезендә раслый.

Конкурста барлык авыл мәдәният учреждениеләре дә катнаша ала.

Конкурс 2018 елның 1 нче апреленнән 15 сентябрь аралыгында түбәндәге этапларда уза:

I нче этап - 2018 елның 1 апреленнән 31 майга кадәр - территорияләрне чистарту буенча санитар-экологик икеайлык;

II этап - 2018 елның 1 июненнән 1 сентябрьгә кадәр - бина фасадларын төзекләндерү, тирә-як территорияләрне яшелләндерү, җиһазлар, бүлмәләрне ремонтлау.

Йомгак ясау өчен материаллар һәм фотографияләр 2018 елның 1 сентябренә кадәр конкурс комиссиясенә тапшырыла.

Оештыру комитеты (кушымта № 1):

- конкурсны үткәрү турында хәбәр итә;
- конкурсның тәртибен, формасын, урынын һәм йомгак ясау датасын билгели;
- конкурска тәкъдим ителгән материалларны карый;
- һәр мәдәният учреждениясенә йөреп чыга ала;
- конкурсның җиңүчеләрен билгели;
- конкурста катнашучыларны бәйге нәтиҗәләре белән таныштыра.

## 4. Бәяләү шартлары

- эш сәгатьләре язылган тышкы мәгълүмәт тактасы булу;
- интерьерларда стиль һәм формалар төрлелеге;
- мәдәният учреждениеләренең эше турында тулы мәгълүмат булу;
- тирә-якны төзекләндерү эшләре буенча балалар һәм өлкәннәр арасында берләшмәләр булдыру (түгәрәкләр, хезмәт отрядлары һ.б.);
- территорияләрне төзекләндерү эшчәнлеге буенча иҗади якын килүне оештыру.

## 5. Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

Конкурс нәтиҗәләре конкурс комиссиясе тарафыннан, алда язылган төркемнәр арасында, 2018 елның сентябрендә күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Кушымта

Мәдәният учреждениеләре арасында территорияне төзекләндерү буенча ел саен үткәрелүче район конкурсының
комиссия составы

Комиссия председателе:

| | | |
|---|---|---|
| Иксанов Д.С. | - | Теләче муниципаль районы башкарма комитеты мәдәният бүлеге җитәкчесе. |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Давлиева Р.М. | - | үзәкләшкән китапханәләр системасы директоры; |
| Нагимова Ф.М. | - | вакытлыча район мәдәният йорты директоры вазыйфаларын башкаручы. |